| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ ШӘҺӘР<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ** |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2019 елның 1 апреле Балык Бистәсе штп. № 4 төп

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 16 октябрендәге 15төп номерлы боерыгы белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибен раслау турында" Эш тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, 2006 елның 2 маендагы "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау турында" 59-ФЗ номерлы Федераль закон, 2018 елның 27 декабрендәге "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм миграция өлкәсендә һәм эчке эшләр өлкәсендә дәүләт идарәсен үзгәртеп оештыру белән бәйле рәвештә "Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисади үсеш территорияләре турында" Федераль законның 22 маддәсе 2 өлеше 2 пунктының көчен югалтуын тану хакында" 528-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә :

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 16 октябрендәге 15төп номерлы боерыгы белән расланган "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибен раслау турында" Эш тәртибенә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 23 маендагы 12төп номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктының дүртенче абзацында "миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, контроль, күзәтчелек һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте федераль органының территориаль органы" сүзләрен "эчке эшләр өлкәсендә дәүләт хакимияте федераль органының территориаль органы" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы, Ленин урамы, 48А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендына Һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче М.В. Мәгыйзов